**«Казан утлары» журналының татар әдәбиятында хикәя жанры үсешенә тәэсире**

Насибуллова Г.Р.,
филология фәннәре кандидаты, КФУ

«Казан утлары» журналы үзенең гасырга якын тарихи яшәешендә татар әдәбиятының җәүһәргә тиң әсәрләрен халыкка җиткерүче мәйдан булып кына калмыйча, тагын да камилрәк әсәрләр иҗат итүгә этәргеч вазифасын да башкара. Басмалар аша татар әдәбиятының үсеш тарихын, үзенчәлекләрен күрергә мөмкин. Журнал һәрвакыт заман белән бергә атлый. Әгәр “Казан утлары”ның барлык саннарын бергә тупласаң, татар әдәбияты тарихын тулаем күрергә мөмкин, бу үзенә күрә бер антологиягә тиң җыентыкка әверелер иде. Журнал әдәби барышның чынбарлыгын чагылдырып кына калмыйча, әле тагын аңа үзгәрешләр кертергә дә сәләтле. Традицион рәвештә үткәрелеп килә торган төрле конкурслар әнә шул хакта сөйли. Бу мәкаләдә журнал битләрендә үткәрелгән хикәяләр конкурсына киңрәк тукталасы килә.

«Казан утлары» журналы, хикәяләр конкурсы игълан итеп, аларның иң яхшыларын елдан артык укучысына тәкъдим итеп барды. Журналның тугыз дистә елдан артык чыккан басмаларын күзәтсәк, әдәбиятның беренче карашка гади дә, әмма гаять үзенчәлекле булган хикәя жанры бервакытта да игътибардан читтә булмаганын күрәбез. Ф.Хөсни, Ә.Еники кебек данлыклы хикәячеләребезнең әсәрләре дә тәүге мәртәбә әлеге басма битләрендә дөнья күрә.

“Казан утлары” журналы басылып чыга башлау еллары нәкъ менә XX гасыр башы татар хикәясенең формалашу, әдәбиятны үзгәртү юлларын эзләү һәм жанрның үз үсешендә югары бер ноктага җитү чоры белән тәңгәл килә, XX йөз ахырында, хәзерге әдәбиятта хикәя жанры янә алгы планга чыга. Бу күренеш үзгәртеп кору чорында татар матбугатының төрлеләнүе белән дә бәйле. Әдәбият белгече Д. Заһидуллина: “Нәкъ менә вакытлы матбугат хикәя кебек кечкенә жанрларны укучыга яратып тәкъдим итә, үзенчәлекле тәҗрибәләр һәм иҗади бәйгеләр мәйданы ролен үти” [1, 199]. – дип раслый.

“Иң яхшы хикәя”, “Иң яхшы чәчмә әсәр” һ.б. кебек бәйгеләр күпләп хикәя иҗат ителүгә китерә. “Казан утлары” журналы үткәргән “Яңа дәвер кешесе” дигән темага багышланган хикәяләр конкурсы да моңа зур этәргеч булды. Жанрга шундый игътибар аның сан ягыннан артуына да, сыйфат ягыннан камилләшүенә тәэсир итә. Ләкин алар арасында әдәби әсәрдән ерак торганнары да шактый. Язучылар әлеге жанр өлкәсендә эзләнүләр алып баралар. Алар хикәя материалында реалистик һәм романтик сюжетны модернистик алымнар, психологик һәм лирик тәэсирлелекне арттыру чаралары, символлар, фәлсәфи фикер белән баету юлларын эзлиләр. Бу чорда Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев кебек күренекле хикәя осталары күләмлерәк жанрга күчү белән һәм Фатих Хөсни, Рафаил Төхфәтуллин кебек язучыларыбыз дөньядан китүләре сәбәпле әлеге жанр югалтулар да кичерә. Тик шулай да Мәгъсум Хуҗин, Фәнис Яруллин, Айдар Хәлим, Әхәт Гаффар, Радик Фәизов, Камил Кәримов, Фәрит Яхин, Әхсән Баян кебек әдипләр классик хикәя традицияләрен дәвам иттерәләр, үстерәләр. Шулай ук әдәбиятка 1980 нче елларда һәм соңрак килгән яңа буын хикәя жанры үсешенә нык тәэсир итә. Галимҗан Гыйльман, Ркаил Зәйдулла, Зиннур Хөснияр, Марат Кәбиров бу жанрның яңа формаларын тудыру юнәлешендә эш алып баралар. XX гасыр ахыры татар әдәбияты мәйданга хатын-кыз прозаиклары килеп керү белән дә үзенчәлекле. Гасыр ахырында әдибәләр иҗат иткән хикәяләр гомуми әдәби процесстан аерылып тора һәм үз сәнгати юнәлешен тудыра. Рифә Рахман, Рәмзия Габделхакова, Фирүзә Җамалетдинова кебек әдибәләр “үз күңелдәгеләрен укучыга гына түгел, геройларының, бигрәк тә героиняларының төп-төгәл рәвешләрендә үзләренә дә аңлашылып җитмәгән чуар психологик халәт айкалышларын, фәкать хатын-кыз логикасы аша гына хәл ителерлек сюжет маҗараларын кызыклы хикәяләргә әверелдерәләр” [2, 88].

Конкурс татар әдәбиятында соңгы елларда шактый активлашып киткән хикәяләрне бергә тупларга ярдәм итте һәм, чыннан да, хикәячеләрнең күплеген күрсәтте. Укучылар әдәбиятыбызның танылган язучылары, хикәя осталары

Мәгъсум Хуҗин, Әхәт Гаффар, Айдар Хәлим һ.б. әсәрләре белән беррәттән әле иҗат дөньясына яңа аяк басучыларның хезмәтләре белән дә танышты.

Конкурска килгән хикәяләрне күзәткәннән соң, аларның тематикасы да, һәр язучының сурәтләү алымнары да төрле икәнлеген күрәбез. Бәйгедә катнашкан кайбер әсәрләргә тукталып үтик. М.Хуҗинның халыкның җиргә мәхәббәтен, телен, милли үзенчәлекләрен югалта баруына борчылулар белән сугарылган “Ипи. Колын. Без.” әсәре хикәяләүнең төрле геройлар исеменнән алып барылуы белән башкалардан аерылып тора. Ә.Гаффарга хас булган көтелмәгән чагыштырулы, тәэсирле сурәтләүле стиле конкурска тәкъдим иткән “Коелы өй” хикәясендә дә чагылыш таба.

Бәйге татар әдәбиятында хатын-кыз хикәячеләребезнең күплеген дә раслады. Э.Шәрифуллина, Р.Рахман, А.Әхмәтгалиева, Х.Ширмән, А.Юнысова, Р.Габделдхакова кебек әдибәләребез дә әлеге жанрны үз итә икән һәм шактый саллы нәтиҗәләргә дә ирешкәннәр. Аларның хикәяләрендә, хатын-кызга, хас булганча, беренче урында хис сурәтләнә. Әдибәләребез безнең дәвер кешесенең дә, беренче нәүбәттә, эчке дөньясына, күңелендә барган бәрелешләргә игътибар итәләр, җыр, шигырь, төсләр, төш һ.б. алымнар ярдәмендә кешенең эчке кичерешләрен алгы планга чыгаралар. Э.Шәрифуллинаның “Уяну”, Х.Ширмәннең “Мәхәббәтнең соңгы көне”, Р.Рахманның “Сөннәтче әби”, А.Әхмәтгалиеваның “Өзелгән гөл” һ.б. әсәрләр хиснең хөкем итүе белән аерылып тора. Бәйге нәтиҗәләре күп шагыйрь-шагыйрәләрнең проза өлкәсендә дә уңышлы эшләвен күрсәтә. Хикәяләрнең күбесе хис тукымасыннан хасил булганы шуның белән аңлашыла да.

“Казан утлары” журналы оештырган хикәяләр бәйгесе аерым кысалар чикләп куя: ул прозаның әлеге кыска күләмле жанрында “Яңа дәвер кешесен” эзләүгә юнәлтелгән. Бер яктан, бу шарт хәзерге әдәбиятта яңа заман кешесенең сурәтләнешен ачыкларга ярдәм итә. Икенче яктан, кысалар язучының ирекен чикли. Ләкин бәйгегә килгән хикәяләрне күзәткәч, без язучыларның әлеге мәсьәләне төрле яклап тикшерергә һәм укучысына җиткерергә тырышуын күрәбез. Бу эзләнү юлында да безнең әдәбиятыбызның төрлелеге ачык

чагылыш таба. Мәсәлән, кайбер хикәячеләребез яңа дәвер кешесен хәзерге заманда үз урынын тапмаган (А.Юнысова “Мадам Бовари”, Х.Ширмән “Мәхәббәтнең соңгы төне”, югалган (Ф.Яхин “Чишелмәс төен”), тормышыннан ваз кичкән (Ф.Гайнуллин “Күчтәнәч”) яисә тормыш төбенә тәгәрәгән герой (И.Сиражи “Күкләр никахы”, К.Кәримов “Сунар вакыты”, Р.Зәйдулла “Кыз-хатын”) буларак күрсәләр, икенче бер әсәрләрдә ул тормышка өмет белән караучы, ныклы адымнар белән атлаучы ир-ат (М.Хуҗин “Ипи. Колын. Без”, М.Хәбибуллин “Өч көнлек көтүче”, Ә.Гаффар “Коелы өй”) һәм гаилә учагын саклаучы, кешелекне барлыкка китерүче ана, хатын-кыз буларак сурәтлиләр (Э.Шәрифуллина “Уяну”, Р.Рахман “Сөннәтче әби” һ.б.).

Бәйгенең нәтиҗәсеннән күренгәнчә, хикәя жанры бүгенге әдәбиятта үсештә, ул камилләшә бара. Конкурс йомгаклары буенча тәнкыйтьчеләр һәм язучылар катнашында үткәрелгән “түгәрәк өстәл” сөйләшүе дә шул хакта сөйли. “Казан утлары” журналының мондый бәйгеләр үткәрүе әдәбиятыбызны барларга, аны тагын да җанландырырга, язучыларыбызны эзләнүләргә этәрә.

Әдәбият


1. Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980 – 2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.
2. Сверигин Р. Хәзерге хикәя / Дискуссия: “Хәзерге хикәя” // Казан утлары. 2009. №5. Б. 88.